ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКТАНЫШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423740, Актанышбаш авылы, Мәктәп ур.,
19 нче йорт. Тел 3-44-39
Email: akt.aktbash@yandex.ru

АКТАНЫШБАШСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423740, д. Актанышбаш, ул. Школьная,
дом 19. Тел 3-44-39
Email: akt.aktbash@yandex.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**«24» апрель 2025 ел**

**КАРАР**
**№11**

Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Актанышбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе турында» 16.03.2020 ел, № 8 (28.02.2025 ел № 7 үзгәрешләр белән) карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Актанышбаш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 16.03.2020 ел, № 8 (28.02.2025 ел № 7 үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Актанышбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.6 пунктыннан түбәндәге эчтәлекле абзацны төшереп калдырырга:

"Салым чыгымнары кураторы тарафыннан бирелгән ташламаларның түләүчеләр тарафыннан таләп ителүен бәяләүне уздыру максатларында әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән ташлама кирәк дип таныла торган чагыштырманың минималь күрсәткече билгеләнергә мөмкин.".

1.2. 3.9_1 пунктын төшереп калдырырга.

1.3. 3.10_1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10_1. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль берәмлекнең техник салым чыгымнарына карата үткәрелми.»

3. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтындагы "Авыл җирлекләре" бүлегендә түбәндәге адрес буенча http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **Маликов Г.Р.**